СОВЕТ СТАРОАЙМАНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423739, село Старое Айманово, ул.Новая,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ АЙМАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423739, Иске Айман авылы, Яна ур..,5А

Тел/факс (885552)5-01-63
Saym.Akt@yandex.ru

**РЕШЕНИЕ**

**№ 14**

**КАРАР**

**от 06.07.2020г.**

**Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлегенең кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив хокукый актларны гамәлдәге кануннарга туры китерү максатларында Актаныш муниципаль районының Иске Айман авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районының Иске Айман авыл җирлеге Советының «Актаныш муниципаль районының Иске Айман авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» 20.09.2007 ел 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а. 1 нче кушымтаның 9 пунктындагы 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «5) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсенең (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклары керми;».

2. Актаныш муниципаль районының Иске Айман авыл җирлеге Советының «Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә яңа редакциядә» 07.09.2017ел 22 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а. Нигезләмәләнең 3.3 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсенең (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклары керми;».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Иске Айман авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Иске Айман авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Иске Айман авыл жирлеге Башлыгы: М.Р.Ахметханов